Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә башкарма комитеты
КАРАРЫ

30 июнь 2021 ел №4

Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләме турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Торак кодексының 156 һәм 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта хезмәт күрсәтүләр һәм идарә итү, тоту һәм ремонт эшләре башкарылган очракта, торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен тиешле сыйфатсыз һәм (яисә) билгеләнгән дәвамлылыктан артып китүче өзеклекләр белән үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» карары нигезендә

Түбән Мактама бистә башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту өчен 2021 елның 01 июленнән 2022 елның 30 июненә кадәр түләү күләмен расларга һәм гамәлгә кертергә (1 нче кушымта).

2. Түбән Мактама бистә башкарма комитетының «Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында

карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләме турында» 2020 елның 30 июнендәге 13 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе, Тихоновка авылы торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2021 елның 1 июленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Түбән Мактама бистә башкарма комитеты җитәкчесе А.Ю. Зарубин

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә
башкарма комитетының
30 июнь 2021ел № 4
карары белән расланган
1 нче кушымта

Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен 2021 елның 01 июленнән 2022 елның 30 июненә кадәр билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләр өчен түләү күләме

| № п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Үлчәү берәмлеге | Айлык тариф |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | сум/кв. м | 2,33 |
| 2. | Гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру | сум/кв. м | 1,56 |
| 3. | Йорт яны территориясен җыештыру | сум/кв. м | 2,22 |
| 4. | Автомат рәвештә бикләнә торган җайланмаларсыз торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | сум/кв. м | 2,33 |
| 5. | Автомат рәвештә бикләнә торган җайланмалары булган торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү (күпфатирлы йортта гомуми мөлкәт составында булганда) | сум/кв. м | 2,72 |
| 6. | Салкын су белән тәэмин итү приборлары белән йорт эчендәге инженерлык салкын су суүткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | сум/кв. м | 2,18 |
| 7. | Салкын су белән тәэмин итү приборларыннан башка йорт эчендәге инженерлык салкын су суүткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | сум/кв. м | 1,99 |
| 8. | Газ белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | сум/кв. м | 0,20 |
| 9. | Электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | сум/кв. м | 0,82 |
| 10. | Дератизация | сум/кв. м | 0,15 |
| 11. | Найм торак урыннары (яллаучылар өчен) | сум/кв. м | 6,11 |

Түбән Мактама бистә башкарма комитеты җитәкчесе А.Ю. Зарубин